ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ИСКЕ СЭФЭР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423748, Иске Сэфэр авылы,
М.Вахитов ур.,
16 нчы йорт. Тел.3-44-55

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОСАФАРОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423748, село Старое Сафарово,
ул. М.Вахитова ,дом 16 , Тел. 3-44-55

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**07 мая 2024 года** **№ 7**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге Башкарма комитетының "Инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 04.06.2021 ел, № 10 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 19 ноябрендәге 1221 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» РФ Хөкүмәтенең 2024 елның 05 февралендәге 124 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Иске Сәфәр авыл җирлеге Башкарма комитетының "Инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 04.06.2021 ел, №10 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Адреслашу объектына адрес бирү яки аның адресын гамәлдән чыгару турында карар кабул итү, адреслашу объектына адреслашудан баш тарту яки аның адресын гамәлдән чыгару турында карар кабул итү, шулай ук адреслашу объектының адресы турында тиешле мәгълүматны дәүләт адрес реестрында урнаштыру вәкаләтле орган тарафыннан башкарыла:

а) кәгазьдә гариза биргән очракта гариза килгән көннән алып 10 эш көненнән дә артык булмаган вакыт эчендә;

б) электрон документ формасында гариза биргән очракта гариза килгән көннән алып 5 эш көненнән дә артык булмаган вакытта.".

2) 2.3.2 пунктында «вәкаләтле орган карары буенча берләшкән булырга мөмкин» сүзләрен «берләшә» сүзенә алмаштырырга.

3) 1.2 пунктның 10 абзацында «Әлеге пунктта күрсәтелгән зат исеменнән» сүзләрен «Гариза белән,» сүзләренә алмаштырырга.

4) 1.5 пунктның 9 нчы абзацында "(шул исәптән торак район, микрорайон, квартал, сәнәгать районы)," сүзләреннән соң, "яр буе," сүзләрен өстәргә;

5) 1.5 пунктының 10 абзацында «яр буе,» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Иске Сәфәр авыл башкарма комитет җитәкчесе А.К.Гиздуллин

«Исполнительный комитет Старосафаровского сельского поселения Актанышского муниципального района» ТАТАРСТАН АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН ОГРН 1061682002392 ИНН 1604006840